**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИӨИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# РЕШЕНИЕ

*№ 8* *Кече Урыссу ав.* *05.10. 2017 ел*

*Ташкичү авыл җирлеге Советының*
*2012 елның 29 мартындагы 6 санлы*
*Карарына үзгәрешләр кертү турында*

Ютазы районы прокурорының 2017 елның 28 августындагы 02-08-01-2017/11 санлы протестын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2012 елның 29 мартындагы 6 санлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләренә (19.06.2014 ел, №11 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1. 3.1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 3.1.1. Территорияне карап тоту һәм җыештыру эшләрен оештыру өчен җаваплылык әлеге территория милек, биләү, файдалану, аренда хокукларында булган затларга йөкләнә.»

1.2. 3.1.2 Пунктны гамәлдән чыгарырга.

1.3. 4.1.1 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 4.1.1 .Җирлек территориясен санитар чистарту һәм карап тоту юридик һәм физик затлар тарафыннан аларның милек, биләү, файдалану, аренда хокукларында, санитар нормаларда һәм кагыйдәләрдә, әлеге Кагыйдәләрдә, башка муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.»

1.4. 5.2.4 пунктында «аның янәшәсендәге территория дә" сүзләрен төшереп калдырырга.

1.5. 5.3.1 пунктында түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга: дүртенче абзац, өченче абзацның өченче тәкъдиме.

1.6. 9.1.2 Пунктны төшереп калдырырга.

1.7. 9.1.3 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 9.1.3.Юридик һәм физик затлар тарафыннан милек, биләү, файдалану, аренда хокукларында булган территорияләр чикләрендә түбәндәге чаралар үткәрелә:

- агачлар һәм куаклар утырту, агротехник таләпләрне үтәп, биналардан һәм корылмалардан рөхсәт ителгән минималь араны исәпкә алып башкарыла;
- чаптырылган үлән 3 тәүлек дәвамында җыештырылырга тиеш;

- чүп-чарны вакытында җыештыру һәм кардан чистарту эшләре алып барыла;

- киселгән агачларны чыгару төп магистральләрдә һәм калган территорияләрдә бер тәүлек дәвамында башкарыла. Сак зонасында (1 м радиуста) агач ботакларын көч линияләре һәм элемтә челтәрләре чыбыкларын үз вакытында кисүне алар карамагында булган оешмалар тәэмин итә.»

1.8. 4.1.1 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 9.1.14. Юридик һәм физик затларның милек, биләү, файдалану, аренда хокукларында булган территорияләре чикләрендә корткычларга һәм яшел үсентеләр авыруларына каршы көрәш буенча кирәкле чаралар үтәлергә, сулыкларның чиста булуын тәэмин итәргә тиеш.»

2. Әлеге карарның үтәлешен үз контролендә тотам.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru> Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы: Р.К.Вәлиев.